# Татарстан Республикасы
# Тукай муниципаль районы
# Шильнебаш авыл җирлеге
# Башкарма комитеты

## КАРАРЫ

17 сентябрь 2018 нче ел Шильнебаш авылы № 11

«Шильнебаш авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 нчы статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 нче елның 12 нче июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 нче статьясы, «җирле референдум турында» 2004 нче елның 25нче мартындагы 23 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 нче статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28 нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлеге башкарма комитеты,

КАРАР ИТӘ

1. Шильнебаш авыл җирлеге Советы белән берлектә Шильнебаш авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турындагы башлангычны җирле референдум сорауларын түбәндәгечә формалаштырып тәкъдим итәргә:
   Шильнебаш авыл җирлеге территориясендә 2019 нчы елда Шильнебаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнардан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә;
   I һәм II группа инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, күпбалалы гаиләләр, ялгыз карт гражданнар, көндезге формада укучы студентлар өчен түләүне 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә.
   Җыелган акчаны түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга :
   - Шилнәбаш авылында янгын сүндерү депосы төзелеше;
   - Шилнәбаш авылында зират коймаларын урнаштыру;
   - Шилнәбаш һәм Тогаево авыллары юлларын ремонтлау.»
2. Әлеге карарны Шильнебаш авыл җирлеге Советына җибәрергә.
3. Әлеге карарны Шильнебаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстемдә калдырам.

Башкарма комитеты җитәкчесе О.А. Гончарова

Исполнительный комитет ШИЛЬНЕБАШСКОГО сельского поселения
ОГРН 1061682004977
ИНН 1639032400